# 2016 нчы елда химиядән дәүләт йомгаклау аттестациясе уздыруның ике имтихан моделе турында
# МӘГЪЛҮМАТ

2016 нчы елда Россия Федерациясе субъектларының мәгариф өлкәсендә идарә итүче башкарма хакимият органнарына, сайлау өчен, химиядән имтихан эшенең ике моделе тәкъдим ителә. Алар арасында төп аерма, **бары тик,** 2 нче өлешнең гамәли-юнәлтелгән биремнәрен эшләү ысулында чагылыш таба:

• *1 нче модель* башка ел имтихан модельләрен үзгәрешсез **кабатлый**;

• *2 нче модель* **реаль химик эксперимент** үткәрүне күздә тота (22 һәм 23 нче биремнәр).

Бу модельләрнең төзелеш үзенчәлекләрен һәм алардагы биремнәрнең формасы турында күзаллауны 2016 нчы елда ХИМИЯдән төп дәүләт имтиханын уздыру өчен контроль үлчәү материалларының *Спецификациясе* һәм *Демонстрацион вариантлары* (№ 1 һәм № 2) бирә.

2 нче имтихан моделе буенча химиядән төп дәүләт имтиханы оештыру өчен зур әзерлек эшләре алып барырга кирәклегенә игътибар итәргә кирәк. Беренчедән, имтиханның эксперименталь өлешендә катнашу өчен, белгечләр әзерләргә зарур. Икенчедән, имтихан уздыру пунктларын лабораторияләр, кирәкле җиһазлар һәм реактивлар белән тәэмин итү таләп ителә.